КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 3 сентябрь г.Казань № 657

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс уздыру турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 683 нче; 2019 ел, 9 август, 669 нчы; 2020 ел, 13 июль, 586 нчы; 2023 ел, 2 май, 550 нче; 2024 ел, 25 гыйнвар, 32 нче; 2024 ел, 18 июль, 579 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Конкурс үткәрү шартлары

6.1. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат Оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://www.tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар» һәм «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурс уздыру шартлары, номинацияләр, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары һәм

тәртибе, урыны, сроклары, заявкаларны бирү тәртибе, бүләкләү күләме һәм рәвеше, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

Әлеге мәгълүмат Конкурска заявкалар кабул итү тәмамланган датага кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

6.2. Әгәр Конкурсның нинди дә булса номинациясенә бер генә заявка бирелгән яки бер заявка да бирелмәгән булса, Конкурста катнашу өчен бу номинациядә бер генә заявка кабул ителгән яки бер заявка да кабул ителмәгән булса, Конкурс бу номинациядә уздырылмаган дип таныла.

6.3. Конкурска узган Конкурска заявкалар кабул итү тәмамланган көннән соң килә торган көннән алып чираттагы Конкурска заявкалар кабул итү тәмамланган көнгә кадәр иҗат ителгән конкурс эшләре тәкъдим ителә.

6.4. Конкурска түбәндәге конкурс эшләре кабул ителә:

анкета-заявкада күрсәтелгән болыт саклагычка сылтама рәвешендә кимендә 15 секунд озынлыктагы телевизион эшләр (тапшырулар, махсус репортажлар, телевизион сюжетлар цикллары һәм башка телевизион эшләр);

җитәкче имзасы һәм юридик зат мөһере белән (булган очракта) яки физик затлар өчен автор имзасы белән таныкланган, анкета-заявкада күрсәтелгән сылтама буенча болыт саклагычка электрон басма рәвешендә урнаштырылган, кимендә 500 билге бирелгән басма массакүләм матбугат чараларында басмалар (басмалар сериясе, махсус чыгарылышлар);

заявка-анкетада актив адреслы сылтамалар рәвешендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә басмалар;

анкета-заявкада күрсәтелгән болыт саклагычка сылтама рәвешендә кимендә 15 секунд озынлыктагы радиоэшләр (тапшырулар, махсус репортажлар, радиосюжетлар цикллары);

6.5. Конкурска тәкъдим ителгән Конкурс эшләре рецензияләнми.

6.6. Конкурска түбәндәге документлар теркәлгән заявка кабул ителә:

1) әлеге Нигезләмәнең 6.4 пунктында бирелгән форматта конкурс эше;

2) әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча катнашуга анкета-заявка;

3) юридик затлар, шул исәптән Татарстан Республикасының СЮККО, юридик зат буларак теркәлгән ММЧ редакцияләре өчен түбәндәге документлар:

салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык (салым түләүченең идентификация номеры);

ММЧ теркәү турында таныклык яки теркәлгән ММЧ реестрыннан өземтә – ММЧ өчен;

4) физик затлар өчен (авторлар, авторлык коллективлары):

шәхесне раслый торган документ:

Оештыручы тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

5) юридик зат булып оешмаган ММЧ редакцияләре өчен:

ММЧ теркәү турында таныклык яки теркәлгән ММЧ реестрыннан өземтә;

ММЧ редакциясе 10 кешедән кимрәк булса, «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының 20 статьясы нигезендә ММЧ редакциясе уставы яисә аны алмаштыручы шартнамә;

е) бергәләп эшләгән конкурс эшләрен бирүче Заявка бирүчеләр өчен: конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта, акчаны процент ягыннан бүлү турында килешү.

6.7. Әлеге Нигезләмәнең 6.6 пунктында күрсәтелгән документлар бөтен документны йә аның фрагментын һәркем файдалана алырлык программа тәэминаты чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган ачык форматлы кәгазь документларның электрон образлары рәвешендә konkurs.sonko.rt@mail.ru электрон почта адресы буенча «Татарстан Республикасының Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс» тамгасы белән тапшырыла. Әлеге пунктта күрсәтелгән документлар, әгәр түләү алуны күздә тотса, мондый программа тәэминатының хокук иясе белән лицензия килешүе яисә башка килешү төзүне таләп итә торган өстәмә программа тәэминатыннан башка үз эчтәлекләре белән таныштыруны тормышка ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланмаска яисә сакланмаска тиеш.

6.8. Конкурс өчен тапшырылган заявка Оештыручы тарафыннан заявка алынган көннән соң эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлә.

6.9. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар Заявка бирүчеләр һәм Катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә түләнә.

6.10. Конкурска йомгаклар Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс эшләрен кабул итеп алу тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә ясала һәм комиссия рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән комиссия утырышы датасыннан алып өч календарь көн эчендә рәсмиләштерелә.

6.11. Заявка бирүчеләр интеллектуаль милек объектларына барлык хокукларның бары Заявка бирүчеләргә генә каравын һәм аларның Оештыручы тарафыннан файдаланылуын интеллектуаль милек турында Россия Федерациясе законнарын һәм (яисә) өченче затларның хокукларын бозмавын гарантияли.

Конкурста катнашуга заявка биргәндә, Заявка бирүче Конкурс үткәрүгә бәйле максатларда Оештыручы тарафыннан конкурс эшләрендәге интеллектуаль милек объектларыннан файдалануга ризалыгын белдерә.

Бирелгән материалга (заявкага) карата өченче яклар тарафыннан нинди дә булса дәгъвалар килеп чыккан очракта, Заявка бирүче аларны, Оештыручыны җәлеп итмичә, тулысынча мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә (өченче якларның турыдан-туры һәм турыдан-туры булмаган зыяннарын каплауны да кертеп) бурычлы.»;

7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Конкурста катнашуга рөхсәт итү яки рөхсәт итүдән баш тарту турында хәбәрнамә заявка алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Оештыручының җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан имзалана, анкета-заявкада күрсәтелгән электрон почта адресына электрон хат белән җибәрелә.

9.7 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

9.8 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 2 декабрь, 885 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 3 сентябрь, 657 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Василова Диана Әнвәр кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе |
| Кадыйров Тимур Рәфкать улы | «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасы халыклары Дуслык йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәммәтшина Даната Владимировна | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының матбугат хезмәтләре белән эшләү һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге баш белгече, конкурс комиссиясе секретаре |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гарифуллин Васил Заһит улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбенең милли һәм глобаль медиа кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге рәисенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Гыйниятов Данил Шамил улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыятенең махсус проектлар редакторы (килешү буенча) |
| Сабурская Алина Викторовна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Сафина Зөлфия Нурмөхәммәт кызы | «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча республика ресурс үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Фазуллин Илназ Фаис улы | Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шакиров Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы (килешү буенча). |